**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ИСКЕ ДӨРЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

«05» октябрь, 2020 ел Иске Дөреш авылы № 9

**«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Иске Дөреш авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы "Иске Дөреш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2020 елның 16 октябренә 10:00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авылы Ленин, К.Маркс һәм Мәктәп урамнарында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын Иске Дөреш авылы , Г.Тукай урамы, 21 йорт янында билгеләргә.
2. 2020 елның 16 октябренә 13:00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авылы Г.Тукай һәм Яшьләр, урамнарында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын Иске Дөреш авылы, Г.Тукай урамы, 21 йорт янында билгеләргә.
3. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, Иске Дөреш авылында яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.
4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2021 елда яшәү урыны буенча Иске Дөреш авыл җирлеге Иске Дөреш авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 600 (алты йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 300 (өч йөз) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

**1. Ленин һәм Г.Тукай урамнарында юллардагы чокырларны ремонтлау.**
**2. Балалар уен мәйданчыгын сатып алу һәм урнаштыру.**

«ӘЙЕ» «ЮК».

5. Халык җыенын оештыручы итеп Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.
6. Әлеге карарны авыл җирлегенең рәсми стендларында, Тукай муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.
7. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Иске Дөреш авыл җирлеге Башлыгы Р.М. Дусадбеков